ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Балыклы авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 2 декабре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәр бала тәрбияләүче ялгыз аналар, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочная хәрби хезмәткә чакырылган затлар; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларны һәм аларның гаилә әгъзалары керми.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы карап тоту , смета документациясен төзү);

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (территорияләрне куаклардан чистарту һәм планлаштыру, чишмәләрне ремонтлау һәм төзекләндерү, материаллар сатып алу, смета документациясе төзү).

3. Элеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче

Муниципаль берәмлек башлыгы Р. Ф. Маликов